СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д.53,
с. Ерыклы,423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы,423185

тел.,факс.:(8-84348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Зирекле авыл җирлеге советы утырышы
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
КАРАРЫ

2021 елның 29 апрель — № 10-26

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 июнендәге 36-57 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү Кагыйдәләре» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, шулай ук, Зирекле авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү объектларын карап тотуга, чисталыкка һәм тәртипкә карата бердәм таләпләр билгеләү, тулаем төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 июнендәге 36-57 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү Кагыйдәләре» карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 6 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә укырга: «территорияне төзекләндерү - муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, мондый территорияләрдә урнашкан торак пунктлар территорияләрен, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналар, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән эшчәнлек;».

1.2 44 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә укырга "әгәр мондый җир участогы барлыкка килгән һәм чикләре Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән булса, аның янәшәсендәге территория - гомуми файдаланудагы территория;".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Яңа

Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының Законлылык, җирдән файдалану һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Зирекле авыл җирлеге башлыгы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Татарстан Республикасы

СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Җ.Г.Гайфетдинов